Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Башлыгы

# КАРАРЫ

15 ноябрь, 2021 ел № 4

## Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 144 номерлы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыеннарын билгеләргә:

1.1. Көлкәмәр авылында. Гражданнар җыенын 2021 елның 27 ноябрендә,10 сәгать 00 минутта, Мәктәп урамы буенча Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар һәйкәле янында үтәчәк.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Көлкәмәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Керәшен Сәрдәсе авылында. Халык җыенын өч этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2021 елның 4 декабрендә 10.00 сәгатьтә Совет урамы, 45 нче йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Татарстан урамы, Совет урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2021 елның 4 декабрендә 12.00 сәгатьтә Гагарина урамы, 135 нче йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Болын, Гагарин урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының өченче этабы 2021 елның 4 декабрендә 14.00 сәгатьтә Яшьләр урамы, 165 нче йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Болын, Гагарин урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

« Сез, 2022 елда Керәшен Сәрдәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов